РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН

СОВЕТ
АЛЬМЕТЬЕВСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ

ӘЛМӘТ
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОН
СОВЕТЫ

**РЕШЕНИЕ** **КАРАР**

«2» ноябрь 2023 г. г. Альметьевск № 260

Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы Советының 2021 елның 15 ноябрендәге 92 номерлы «Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы территориясендә муниципаль торак контроле турында нигезләмәне раслау хакында»гы карарына үзгәрешләр кертү турында

Россия Федерациясе Торак кодексы, «Россия Федерациясендә дәүләт контроле (күзәтчелеге) һәм муниципаль контроль турында» 2020 елның 31 июлендәге 248-ФЗ номерлы, «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы федераль законнар нигезендә, Татарстан Республикасы икътисад министрлыгының 2023 елның 12 октябрендәге 01-54/7098 номерлы хатын исәпкә алып

Әлмәт муниципаль районы Советы КАРАР БИРӘ:

1. «Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы территориясендә муниципаль торак контроле турында нигезләмәне раслау хакында» 2021 елның 15 ноябрендәге 92 номерлы Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы Советы карарына (Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы Советының 2021 елның 16 декабрендәге 112 номерлы, 2022 елның 13 июлендәге 154 номерлы, 2023 елның 16 июлендәге 230 номерлы карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) түбәндәге үзгәрешне кертергә:

карарның 2 нче кушымтасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Мәҗбүри таләпләрне бозу куркынычы индикаторлары, муниципаль контрольне гамәлгә ашырганда контроль чараларын уздыру өчен нигезләр буларак кулланыла торган

1. Кен тәртибендәге шундый ук мәсьәләләр буенча хәл ителгән муниципаль торак фондының торак урыннары булган күпфатирлы йортта урыннар милекчеләренең гомуми җыелышының еч ай рәттән ике һәм аннан да күбрәк беркетмәләре муниципаль торак контроле органына керү.

2. Дәүләт торак күзәтчелеге органы, муниципаль торак контроле органы адресына кергән (мөрәҗәгать иткән гражданның шәхесен ачыкларга мөмкинлек

биргән ысул) һәм күпфатирлы йорттагы урыннар милекчеләре булган оешмаларның, дәүләт хакимияте органнарыннан, җирле үзидарә органнарыннан, массакүләм мәгълүмат чараларыннан, «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәреннән мәгълүмат, Россия Федерациясе Торак кодексының 20 статьясындагы 1 өлешендә билгеләнгән мәҗбүри таләпләрне бозуларны контрольдә тотучы затлар турындагы дәүләт мәгълүмат белән чагыштырганда вакыт берәмлеге (ай, квартал) өчен мөрәҗәгатьләр санының өч мәртәбә һәм аннан күбрәк үсеше.

3. Торак-коммуналь хуҗалыкның дәүләт мәгълүмат системасында Россия Федерациясе Торак кодексының 165 статьясындагы 5 өлеше нигезендә билгеләнгән урнаштыру тәртибе, рәвешләре, сроклары һәм вакыты нигезендә урнаштырылырга тиешле мәгълүматны актуальләштерүнең өч һәм аннан артык ай дәвамында булмавы.

4. Тикшерелә торган зат идарәсендә булган күпфатирлы йортта гомуми милекнең тезексезлеген бетерү эшләрен уздыру өчен атнасына биштән артык очрак ремонт бригадаларын чакыру, Бердәм диспетчерлык хезмәте мәгълүматы буенча.

5. Торак-коммуналь хуҗалыкның дәүләт мәгълүмат системасында урнаштырылган торак-коммуналь хезмәтләр өчен түләүгә түләү документларында күпфатирлы йорт биналары милекчеләренең гомуми мелкәтен файдаланганда һәм карап тотканда кулланыла торган коммуналь ресурслар өчен түләү күләмен алдагы шундый ук хисап чоры белән чагыштырганда 50 %тан артыкка арттыру турындагы белешмәләрне ачыклау.».

2. Әлеге карарны «Альметьевский вестник» газетасында бастырып чыгарырга, «Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталы» (PRAVO.TATARSTAN.RU) һәм Әлмәт муниципаль районы сайтында «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә урнаштырырга.

3. Әлеге карар рәсми басылып чыкканнан соң үз көченә керә.

4. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны районның икътисадый үсеш, торак-коммуналь хуҗалык һәм муниципаль милек мәсьәләләре буенча даими комиссиясенә йөкләргә.

Муниципаль район Башлыгы Т.Д. Нагуманов